Теләп алган бәхет һәм фаҗига: "Туташ" документаль романының авторы Айгөл Әхмхтгалиева белән әңгәмә // Мәдәни җомга. - 2022. - №46 (25 ноябрь). - Б. 8-9

Теләп алган бәхет һәм фаҗига

Данга күмелеп яшәгән, әмма ялгызлыкта вафат булган сәхнә йолдызы, татар халкының беренче актрисасы Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның тууына 130 ел.

«Туташ» документаль романының авторы Айгөл Әхмәтгалиева белән әңгәмә

– Айгөл ханым, актрисаның тормышын өйрәнгәндә иң тетрәндергече ни иде?

– Аның тормышын ике ел өйрәндем, 2019 елда «Туташ» китабы дөнья күрде. Аңа кадәр Сәхипҗамалны беренче татар артисткасы буларак һәм төрле шәһәрләрдә театр труппалары ачуы турында гына белә идем. Галимнәр һәм язучыларның аның турында документаль язмалары бар, шөкер. Әмма аның биографиясендә ак таплар, ачыкланмаган фактлар шактый. Кайда, кайчан туган – бернинди дә документ юк диярлек. Без аның май аенда туганын да беләбез. Тукай аңа энже чәчәкләрен нәкъ туган көненә бүләк иткәне билгеле. Туган елы белән дә шул ук мәрәкә. Үз көндәлекләрендә туган елын өч дәфтәрдә өч төрле итеп күрсәткән. Ул әтисен Яшел Үзәннең Әрә авылыннан дип яза, Казан, Уфа, Ижау архивларында, бу авылда аның әтисенә кагылышлы бер генә документ та табылмады. Ул үзен ярлы гаиләдән дип тасвирлый, әмма бу да бер хәйлә була ала. Затлы мулла нәселеннән булучыларның күбесе, совет сәясәтен аңлап, үзләрен ярлы крестьян гаиләсеннән дип сөйләргә мәҗбүр булган. Сәхипҗамалның ярлы гаиләдә тууына ышануы читен, чөнки ул башта мәдрәсәдә дини белем ала, аннары Маһруй Мозаффария укыткан кызлар өчен урыс-татар мәктәбендә укый. Бу – элита мәктәбе. Өстәвенә, бал бөюләре мәктәбенә йөри. Анда уку чыгымнар таләп иткән. Шуңа да аның үзен ярлы гаиләдә тудым дип тасвирлавы ул чордагы язылмаган кануннарга буйсынудан тугандыр.

Ижау архивында ире белән никахлашу документы табылды. Анда актрисаның туган җире итеп Чуашстанның Козловский районы Әлмән авылы язылган. Соңрак архивта әтисе Гыйззәтулла Хәмидуллинның документлары да нәкъ шунда туганлыгын раслады. Әтисенең бертуган абыйлары турында да мәгълүматлар бар. Димәк, Волжскаяның нәсел тамыры – Әлмән авылыннан.

Ул әни булу бәхетенә ирешә алмый. Бик күп эшләү, гастрольләрдә ачлы-туклы йөрүләр аркасында аның саулыгы тәмам туза. Үпкәсе белән дә, ашказаны белән дә проблемалары була. Сәхнәдә эшләү бәрабәренә ул әни булу бәхетеннән мәхрүм кала.

– Бәлки, сез үзегезнең күзлектән чыгып, мондый нәтиҗә ясыйсыздыр, кемдер гаилә, бала табуны бәхет дип санамаска да мөмкин.

– Бу фараз түгел. Актриса Ижауда яшәгәндә аның янына язучы Гази Кашшаф килә һәм аның белән әңгәмәдә Сәхипҗамал бу темага да кагыла. «Кызганыч, бер бала алып кайткан идек, ул кайту белән үлде», – ди. Авыру булу сәбәпле мин бала таба алмадым, дигән истәлекләре дә бар. Сәхнәне өстен кую гына булмаган, ана бәхетен татый алмавына үкенү хисләре кичерә. Шулай да алар ире белән олыгайгач тәрбиягә бала алып кайта. Сугыштан соң Ижауда «балалар йортын ябабыз, балаларны таратабыз», – дигән хәбәр чыккач, актриса ире белән үзләренә асрамага мәктәп укучысы яшендә бер кызны сайлаган. Аның бертуган энесеме, абыйсымы да булган. Балалар йорты мөдире икесен дә алырга, аермаска сорый, әмма актриса кыз бала гына кирәк, дип кырт кисә. Ул кызның исемен кемдер Неля ди, кемдер Сәхипҗамалның аңа Асия дип дәшкәнен әйтә. Күршеләре актриса һәр иртәне ул баланың чәчләрен үреп, тасмалар тагып мәктәпкә үзе озатты, көн саен каршы алды, дип искә ала. Шулай да ул кызга кырысрак булды диләр, артык чәпчемәгән, назламыйча, кочакламыйча, үзенчә яраткан. Ә ире Владимир Русинов аны үз баласы кебек яратты, диләр. Кыз баланың язмышы билгесез, медицина институтын бетергәч, Яңа Чабаксар шәһәренә эшкә киткән. Һөнәре – табиб. Мин аны да эзләдем, ләкин таба алмадым. Баштагы мәлдә картлар йортына эләккән Сәхипҗамал янына асрамага алган кызы килеп йөргән дип әйтләләр, аннары юк булган. Ни өчен янәшәсендә калмаган дигән сорауларга җавап юк.

– Яшүсмер кызга сәхнәгә чыгарга Фатих Әмирхан тәкъдим итә. Бу татар дөньясында бомба шартлауга тиң була. Йөзе капланмаган килеш ирләр рәтендә бар кеше хозурына чыгу – ул вакытта башка сыймаслык гамәл. Ни өчен нәкъ менә Сәхипҗамал?

– Сәхипҗамалның таланты, даны, һөнәре – Аллаһ биргән, шул ук вакытта үзе теләп алган бәхете һәм фаҗигасе дә. Аның белән аралашкан кешеләр барысы да аны коеп куйган артист иде, ди. Аның тавышы матур булган, икенчедән, бик хисле иде, диләр. Талант иясе. Образларны үтемле итеп күрсәтә алган. Һичшиксез, кыю кеше. Башкаларда да талант яшәгәндәр, әмма беренчеләрдән булырга Сәхипҗамал батырчылык иткән.

Мәктәптә укыганда ул урыс театрына йөри, театр белән женләнә. Татар театры туып кына килә, әмма анда ирләр генә уйный. Сәхипҗамал – Фатих Әмирхан белән күрше яшәгән кыз, ә ул – заманның иң прогрессив фикер ияләренең берсе. Габдулла Тукай, Хөсәен Ямашев белән дус. Шәһәр яшьләре бергә кайнашкан, милли үзаң ачылган вакыт, ник татарлар ябылып яши, ник татар шулкадәр консерватив дигән сорауларга бимазалый. Шәригать кануннары көчле заман булса да, Сәхипҗамал театр идеясе белән янып, ярамый дигәнне атлап чыга; бәлки, башкалар да артымнан иярер дип уйлагандыр.

– Беренче татар актрисасы дигән данлы исем белән бергә аны тел белән мыскыллау белән чикләнмиләр, куып тотып кыйныйлар, буып үтерергә маташалар, Җаекта гастрольләргә барганда аңа хәтта пистолеттан аталар, чак кына исән кала... Бүгенге көн терминнары белән әйткәндә, буллинг корбанына әйләнә. Аны патриархаль җәмгыять кабул итми. Мондый хәлләр булуын белсә, чамаласа, бу адымга барыр идеме икән?

– Белгән, чамалаган булса да, ул кире борылмас иде. Сәхнә белән агуланган кеше үз хыялыннан баш тартмый. Табигатьләре шундый. Менә бүген артистларга карыйм, әлбәттә, XX гасыр башындагы шартлар белән чагыштырып булмый, әмма алар кечкенә хезмәт хакы алуга, тәүлек буена балаларын да онытып эшләргә туры килүгә, эт булып аруларына карамастан, сәхнәдән баш тарта алмыйлар. Сәхипҗамал да сәхнәдән ваз кичә алмаган. Әйе, аны җәберлиләр, ачлыкта, фәкыйрьлектә яшәгән чаклары күп була, аңа даими яныйлар, әмма ул татар театрын булдырам дигән идея белән яши.

– Сәхипҗамал Волжская – татарның иң кыю феминисты. Ул татар хатын-кызы да театрда эшләргә хаклы һәм гомумән хатын-кызлар ничек тели, шулай яшәргә хокуклы дип үз үрнәгендә күрсәтә. Патриархаль яшәешкә протест күрсәтү кебек яңгырый. Ул гомер буена мин булдырам, хатын-кызлар булдыра, татарлар менә шундый дип яшәгән дигән хис туа.

– Сәхипҗамал тормышын өйрәнү миндә күптөрле каршылыклы фикер тудырды. Аның шәригать кануннарын атлап чыгуы барыбер сораулар калдырды. Ул вакытта сәхнәгә аяк баскан хатын-кызлар әти-әни фатихасыннан баш тарткан. Хатын-кызмы, ир-атмы – бу гамәл бер кешене дә бәхетле итми. Сәхипҗамал – дини тәрбия алган кеше, ул чорда йөзен ачып, чәчен капламыйча кеше хозурына чыгу кая алып барганын, алда бәхет көтмәгәнен чамалагандыр. Бәлки, чамалап та бетермәгәндер. Кыз бала гына булган бит.

Ләкин шушы адымга бармаса, үзен корбан итмәсә, безнең бүген гөрләп торган театрларыбыз булыр идеме? Татар театры – безнең йөзек кашыбыз. Сәхипҗамалны хатын-кыз буларак кызганам. Кирәк булганмы бу корбан, юкмы дигән эчке бәрелеш бар. Өйдә тәти хатын булып яшәү дә, бәлки, аны бәхетле итәр иде, әмма милләт өчен бу югалту булыр иде. Үзен корбан итеп, сәнгатькә фидакәр хезмәт итүе өчен без аңа рәхмәтле булырга тиеш.

Ә патриархаль җәмгыятькә килгәндә, мин бүген хатын-кызлар үзенең асылын онытып бара дип, дилбегәне үзебезгә алуны артык дип саныйм. Акча да эшлибез, идарә дә итәбез, машина да йөртәбез, ирләр белән беррәттән чабабыз... Аллаһ Тәгалә юкка гына ирләр һәм хатыннар рәвешендә безне төрле итеп яратмаган, төрле сыйфатлар белән биләмәгән, ул табигатьне бозарга кирәкми.

– Актрисаның мемуарында кызык бер тарих бар. Татар труппасы белән Семей шәһәренә бара һәм аларга анда спектакль куярга сәхнә бирмиләр. Башта татарның театры бармы дип мыскыл итәләр, аннары ничек инде татарча спектакль куясыз, бәлки, сез анда патшаны хурлыйсыздыр дип цензура кертәләр һәм тәүлек эчендә шәһәрдән китәргә кушалар. Актриса хурлана, әмма шәһәрдән китми, труппа ачлы-туклы яши, әмма сәхнә табып спектакль күрсәтә. Бу – патша заманы. Совет вакытында да, хәзер дә татарларга карата, татар телендәге проектларга карата «ә бәлки сез каршы эшлисездер» дигән сылтау белән эш ителә. Шул сылтау белән милли мәгариф тә тар-мар ителеп килә, театрлар да күзәтү астында.

– Сәхипҗамалны бик милли җанлы кеше дип күзаллыйм, ул чыннан да татарда ни өчен бусы юк, ни өчен без ябылып яшибез дип үкәтләнеп эшли һәм яши.

● С.Гыйззәтуллина-Волжская җәмәгате Владимир Русинов белән. Ижау. 1924 еллар.

Ул булсын дип тырыша. Сез искә алган сюжет аның татар өчен янып-көеп яшәвенең бер кечкенә мисалы. Ул татар сәнгате урысныкыннан ким булмаска тиеш дигән фикер белән яши һәм шул юнәлештә эшли.

Үзем театрларны Мәскәү сәясәте астында дип әйтә алмыйм. Татар театрлары күп очракта ирекле эш итә, үз фикерен житкереп килә. Ниндидер коточкыч цензура астында эшлибез дип тә булмый (А.Әхмәтгалиева Чаллы драма театрында әдәби бүлекне житәкли – ред.). Әмма мәктәпләрдәге татар теле белән булган вәзгыять – ул йөрәк авыртуы һәм бу чыннан да Россия сәясәте басымы белән эшләнде. Кызганычка, Татарстан берни эшли алмады, хәтта татар теле кирәкми диючеләрнең күп өлеше үзебезнең татар кешеләре булып чыкты. Бу – халык белән эшли белмәү нәтиҗәсеме, татар теленә карата мөнәсәбәт нәтиҗәсе булдымы – төпле анализ ясыйсы бар.

– Бер яктан актриса татарлар туган телендә сәхнәдә үз әсәрләрен куярга хаклы дип аяк терәп тарткалаша, икенче яктан урыс теле, мәдәниятенә мөкиббән киткән дигән хис кала. Фамилиясенә урысчалатып «Волжская» өлешен ости, мемуарларында урыс режиссерлары, актерлары турында мөкиббән китеп яза, ул вакытта гадәттән тыш хәл булып саналса да, урыс кешесенә кияүгә чыга. Бу кимсенү комплексымы яки мода, мөгез чыгару булганмы?

– Әйе, ул вакытта катнаш никахлар сирәк күренеш булган, әмма ул мөгез чыгару яки шаккатыру өчен махсус урыс кешесе белән гаилә корыйм әле, димәгәндер. Актриса бик соң кияүгә чыга. 41 яшендә була ул, ә Владимир Русинов аңардан 9 яшькә кечерәк тә әле. Кечкенә деталь – никахларын теркәгәндә, Сәхипҗамалның яшен 21 яшь дип язалар. Хатамы, әллә махсус шулай язганнармы – белмим. Алар 1921 елның 8 гыйнварында язылышкан. Кияүгә чыгуы зур мәхәббәттән дә булмагандыр. Шулай да Сәхипҗамалны хәтерләүчеләр Русиновның аңа карата бик җылы карашта булганын, аның көен көйләп, һәрвакыт булышуын сөйлиләр.

Актриса – үзен беренче итеп күрергә күнеккән кеше, уйлаганын туры әйткән, капризлары да, мин-минлеге дә җитәрлек. Кияүгә чыкканда бер кочак чире була, әле үпкәсе, әле ашказаны авырта, болар хакында шул чордагы медицина белешмәләре сөйли. Ире аны бала кебек тәрбияләгән. Бәлки, Сәхипҗамал кияүгә чыгарга кирәк, тормышта таянырлык кеше булсын, дип никахлашкандыр. Аларның күршеләре Русиновны чуаш иде бугай, дип тә сөйли. Сүз уңаеннан, ул бай нәселдән, большевикларның сәясәтен кабул итә алмыйча аның эти-әнисе чит илгә китә, Владимир Николаевич исә шәһәрдә кала. Русинов ул вакытта Ижау шәһәренең башкарма комитет сәркатибе була. Ул Сәхипҗамал эшләгән рус театрына килеп йөргән, шунда танышып, аннан никахлашканнар.

Ә артистка үзе Казанга кайтырга тели, татар театрында уйнарга хыяллана. Кайта, әмма Казанда инде ул түгел, ә башкалар йолдыз. Афишада, матбугатта – Тинчурин белән Болгарская исемнәре. Аңа төп рольләрне бирмиләр. Актриса моңа гарьләнә, мин Казанга вак-төяк рольләр уйнарга кайтмадым дип үпкәләп, кире Ижауга китә. Ә анда – урыс театры. Ул шунда уйный, әмма бу аны канәгатьләндерми. Сәхипҗамал заводтагы эшче татар кызлар-егетләрен туплап, татарча театр түгәрәкләре өештыра. Мәрзия Миңлебаева аның театр түгәрәгенә йөреп данлыклы артисткага әверелә. Димәк, Волжская татарлыкка тартылу, сусау белән эшләгән.

– Актрисаның мемуарларын укыганда ул большевиклар фанаты булган дигән фикер туа. Кызылларны яклап язуы нәрсәне аңлата: Сәхипҗамал инкыйлабны куанып каршы алганмы, яки бу аның ниндидер бер хәйлә белән сакланырга тырышуымы? Кызыл террор вакытында татар зыялыларының байтагы, ялган донос нигезендә кулга алынып, төрмәгә утыртыла. Күпләрне атып үтергәннәр, кемдер сөргенгә жибәрелгән. Алар арасында татар драматурглары, артистлар, режиссерлар бар. Гажәп, Сәхипҗамал Сталин тегермәненә эләкми кала.

– Үзен ярлы гаиләдән дип ассызыклаганын әйттем, әмма бу алай түгел. Казанда үз йортлары белән яшәгән алар. Эзли торгач, Ижауда аның бертуган апасы яшәгәнен ачыкладык. Гражданнар сугышы башланганда алар бөтен хәзинәләрен алып Ижауга килеп төпләнгән. Азмы-күпме житеш тормышта яшәгәннәр. Аннары, һәр кешегә үз тормышы кадерле. Сәхипҗамал гомерен саклап калу бәрабәренә яңа сәясәтне кабул итәргә мәҗбүр булган. Большевикларга каршы чыкканнарның язмышы ничек тәмамланганын үз күзләре белән күргән. Кемне атканнар, кемне ат койрыгына бәйләп өстерәп үтергәннәр, кемне асканнар. Дини тәрбия алган, күңелендә Аллаһка ышану булган актрисаның кеше рухына кизәнгән сәясәтне җаны белән кабул итүенә ышанып бетә алмыйм.

Кызыл террор елларында актриса ничек исән калган дигән сорауга жавап мондыйрак. Ул вакытта аның ире Русинов Ижауда НКВД системында эшли, ул озак еллар «особый сектор» бүлеген житәкләгән. Авызны чамалап ачарга, карашларны яңа заман таләпләренә салып үзгәртергә туры килүен бәлки ул да аңлаткандыр...

– Кәрим Тинчурин, Габдулла Кариев, Мохтар Мутин һәм башкаларны хокем иткәндә актрисаның роле ниндиби була? Ул аларның төрмәгә эләгүенә булышамы, әллә НКВД аны кулланганмы?

– Театр тарихын өйрәнгәндә КГБның кайбер архив документлары белән танышырга туры килде. Халык дошманнарын эзләү, ачыклау, шпионнарны фаш итү җыеннары – бу чорның куркыныч битләре. Театр утырышлары хәзерге К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры бинасында була. Ул вакытта Сәхипҗамал Ижауда яши, әмма бер җыелышка аны да чакыралар. Ире белән килүе билгеле. Аның ясаган чыгышлары сакланып калган. Җыелышны театрның парторгы Ишморатова алып бара. Сөйләшү беркетмәләренең күп өлеше «Туташ» романында бар. «Габдулла Кариев театрны таркаттымы?» – дип сорыйлар. Сәхипҗамал: «Кариевны гаепләү урынсыз, акчабыз да житмәде, артистлар котыртуга бирелеп, үпкәләшләр аркасында таркалдык», – ди. Спектакльләрдән акча керми иде, Кариев безне ничек туйдыра алсын», – дип сөйли.

Тинчуриннар белән уртак фикергә килә алмыйча Ижауга чыгып китүенең сәбәпләрен сорыйлар. Актриса, туры сүзле булуым өчен мине яратмадылар, Казанга кайтсам да, миңа роль бирергә ашыкмадылар дип сөйләп, Тинчурин белән Болгарскаяга үпкәсен белдерә. Тинчурин һаман яшь егетләрне уйнап йөри дип тә чеметеп ала, әмма шул ук вакытта алардан халык дошманы да ясамый.

– Актрисаның соңгы еллары күп сораулар тудыра. Кайда үлә, ничек, кайчан җирләнә – гел буталчык мәгълүматлар. Аның җәсәден бер кабердән казып алып икенче кабер казу тарихында ачыклык бармы?

– Сәхипҗамал Казанга кайту хыялыннан баш тартмый, мин татар театрына кирәк, Казанымда үлеп, Тукай янында җирләнергә телим дип яши. Ул мондый эчтәлекле хатларны ТАССРның дәүләт оешмаларына юллый. Ире картайган көндә күченеп китүне өнәми, әмма Сәхипҗамал барыбер үзенекен итә. Кайталар, аларга Яңа бистәдә, Камил Якуб урамы, 2 нче йортта фатир бирәләр. Ире чирләп китә, психик авырулар диспансерына эләгә һәм шунда вафат була. Аннары актриса: «Мин бу фатирда тора алмыйм, иремнең өрәге яшәргә ирек бирми», – дип җәфалана һәм аңа фатирны Карл Маркс урамына алыштырырга ярдәм итәләр. Татар театрына якын гына. Волжская театрга гел йөрермен, дип хыяллана, мин театрга кирәк дип уйлый. Әмма ул теләгәнчә булмый, ара-тирә театр училищесына, премьераларга чакыралар, тик бу гына житәрлекме... Үзенең кирәклеген тоеп, дәрәҗәсен белүләрен теләде дип сөйлиләр. Мондый мөнәсәбәт күрмәгәч, үзенә йомылган.

Берара театр мөдире Рәшидә Җиһаншина янына Волжскаяның күршеләре килеп, актриса урамдагы песиләрне жыя, алар белән сөйләшә, кайчак өен таба алмый, оныта, адаша, газны ачып калдырыр дип куркабыз, дип зарлана. Бу – шаһитларның хатирәләре. Сәхипҗамалның күршесендә яшәгән Равил Шәрәфи дә, аның, өен онытып, озатып куярга соравы турында хәтерли. «Хәле чыннан да начарайган, авыруы көчәйгән, туганнары булмагач, караулы, тук булыр» дип Дәрвишләр бистәсендәге картлар йортына урнаштыралар. Мин актрисаны кабул иткән, караган табибны эзләп таптым. Кәүсәрия апа исән-сау, ул аны яхшы хәтерли. Картлар йортында Сәхипҗамал апаның чире аза башлады, Волков урамындагы психодиспансер табибларына күрсәтергә алып бардык, дип сөйләде. Аңа деменция диагнозы куела һәм Чистай шәһәрендәге психоневрологик интернатка урнаштырырга дигән фикергә киләләр. Картлар йортыннан аны машинага утыртып, бер шәфкать туташы озата бара.

Чистайда Сәхипҗамал яткан вакытта эшләгән шәфкать туташын эзләп таптым. Ул аның ябык, хәлсез булуын, орден тагылган пәлтә кигән килеш алып килүләрен хәтерли. Үзе белән песи ияртеп килгән. Кашык тотып үзе ашый алмый, берсен дә танымый, сорауларга жавап бирми иде, дип сөйли ул ханым актриса турында. Озак яшәми анда Сәхипҗамал, шунда вафат була. Аны интернат янындагы зиратта башкалар кебек үк, исем-фамилиясез генә, номер белән генә жирлиләр. Хәнифә апа безгә зират булган урынны да күрсәтте. Берничә айдан соң Чистайга кинәт кенә Казаннан кешеләр килеп төшә. Алар Югары Совет президиумы рәисе Салих Батыев фәрманын – данлыклы татар артисткасының Тукай янында җирләнергә телим дигән васыятен үтәргә тиешбез дип аңлаталар. Ягъни аның җәсәде тиз арада Чистай зиратыннан Казандагы Татар зиратына күчерелергә тиеш. Төп бурыч СССРның халык артисты Фуат Халитовка йөкләнә. Төнлә кабер казыла, сөякләрне полиэтиленга төреп, шул ук төнне Казанга алып китәләр. Татар зиратында жирләү эшләре башкарыла. Тукай янында актрисаның кабер ташы куела. Алып киткән сөякләр чыннан да Волжскаяныкы һәм чыннан да Тукай янында ул жирләгәндер дип уйлыйк. Алай түгел икән, гөнаһлыларны Аллаһ үзе кичерсен. Шушы жирләүдә катнашкан кешеләргә аерым бүләкләр дә бирелә, күрәсең, авызларын яптырыр өчендер...

Сәхипҗамал Волжская турында галим Жәүдәт Миңнуллин да жентекләп өйрәнгән. Ул да тарихи документлар юк дип сөйләде. Гәрчә актриса озын гомер кичерә, ул күп вакыйгаларга тере шаһит була. Ваемсызлыгыбыз, шәхесләр белән кызыксынмавыбыз, аларны барлый белмәвебез, зурламавыбыз аркасында, кызганыч, күпне югалтабыз.

Интернет челтәреннән алынды.